**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-478 номерлы, 2020 елның 18 февралендәге ПУ-100 номерлы, 2020 елның 4 мартындагы ПУ-136 номерлы, 2020 елның 12 декабрендәге ПУ-837 номерлы, 2021 елның 29 маендагы ПУ-412 номерлы һәм 2022 елның 7 июнендәге ПУ-399 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.Х. Газизовны, Д.А. Таюрскийны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Баклашов Антон Николаевичны – «ОПОРА РОССИИ» Гомумроссия кече һәм урта эшкуарлык җәмәгать оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе рәисен (килешү буенча);

Сафин Ленар Ринат улын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

О.В. Коробченконың – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры»;

А.А. Калачевның – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

Б.И. Сәлимҗановның – «Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Укыту-методика үзәге» федераль дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе (Казан шәһәре) директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 12 сентябрь
№ ПУ-638